КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 24 декабрь г.Казань № 1139

2025 елда «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә «Приоритет-2030» стратегияле академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында, аэрокосмос, транспорт, фотон һәм квант системалары өлкәсендә мәгариф программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру буенча яңа суверен технологик линияләр булдырып тикшеренүләр үткәрү максатларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү грантын бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Рәисенең «Приоритет-2030» стратегияле академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында аэрокосмик, транспорт, фотон һәм квант системалары өлкәсендә эшләнмәләрнең яңа суверен технологик линияләрен булдырып тикшеренүләр уздыру һәм мәгариф программаларын гамәлгә ашыру максатларында 2025 елга югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү грантын гамәлгә кую турында» 2025 елның 17 октябрендәге 869 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2025 елда «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә «Приоритет-2030» стратегияле академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында, аэрокосмос, транспорт, фотон һәм квант

системалары өлкәсендә мәгариф программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру буенча яңа суверен технологик линияләр булдырып тикшеренүләр үткәрү максатларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү грантын бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин